| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2019 Алексеевск ш.т.б. № 43

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданчыкларда авиация эшләрен, парашют белән сикерүләрне, һава судноларының күрсәтмә очышларын үткәрү, пилотсыз очу аппаратлары очуларын оештыру, бәйләүле аэростатларныһавага күтәрү, утырту (очу) буенча рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 11 октябрендәге 355 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданчыкларда авиация эшләрен, парашют белән сикерүләрне, һава судноларының күрсәтмә очышларын үткәрү, пилотсыз очу аппаратлары очуларын оештыру, бәйләүле аэростатларны һавага күтәрү, утырту (очу) буенча рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 11 октябрендәге 355 номерлы карарына үзгәрешләр кертепФедераль закон таләпләренә туры китерү максатларында

**карар бирәм:**

1. 5 бүлекне «Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.1 өлештә каралган оешмалар

яисә аларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү» яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ Федераль законның 15.1 матдәсендә күрсәтелгән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорауны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документларны яисә мәгълүматны сорау яки норматив актларда каралмаган эшләрне, гамәлләрне тәкъдим итү яисә башкаруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр баш тарту нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, әлеге Федераль законның 16 матдәсендәге 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда күздә тотылмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүчеорганның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүчеорганның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.1 өлештә каралган

оешмаларның хезмәткәре яисә аларның хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда ясалган ялгышлар һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә мондый төзәтмәләр кертү өчен билгеләнгән срокны бозу.Күрсәтелгәночракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

8) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору.Күрсәтелгәночракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

10) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән, документлары булмау яки алардагы мәгълүмат дөрес булмау сәбәпле беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә 210-ФЗ Федераль законның 7 матдәсендәге 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, әлеге хезмәтләрне күрсәтү өчен документлар яисә мәгълүмат таләп итү. Күрсәтелгәночракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе, 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә йөкләнгән очракта мөмкин;

5.2. Мөрәҗәгать итүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алуга хокуклы.

5.3. Шикаять кәгазьдә, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүче органга яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәкнеңучредителе булган (алга таба – күпфункцияле үзәкнен учредителе) дәүләт хакимиятенең тиешле органына (җирле үзидарә органына),шулай ук 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.1 өлештәкаралган оешмагаязмача тапшырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган

җитәкчесенең яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата булган шикаятьләр алардан югарырак органга (булган очракта) бирелә,андый орган булмаганда шикаятьләр турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның җитәкчесе тарафыннан карала.Күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәкнең җитәкчесенә тапшырыла. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата булган шикаятьләр вәкаләтләреРоссия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән билгеләнгән күпфункцияле үзәкнең учредителенә яисә вазыйфаи затка тапшырыла.210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.1 өлешендә каралган оешмахезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаятьләр әлеге оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең, дәүләти яки муниципаль хезмәткәренең, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаятьләр почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең төбәк порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итүе вакытында да кабул ителергә мөмкин.

Күп функцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаятьләр почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында да кабул ителергә мөмкин.210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.1 өлештә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаятьләр почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында да кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның атамасы, яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының исеме,яисә муниципаль

хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.1 өлештә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләре һәм (яисә) хезмәткәрләренең, карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган органнарның исме;

2) мөрәҗәгать итүче физик зат булса, аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны яисә мөрәҗәгать итүче юридик зат булса, аның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номеры), электрон почта адресы (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (адресы);

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның взифаи заты, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, яисә дәүләти яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең яки хезмәткәрләренең, оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең, вазифаи затларының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченендәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның взифаи заты, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, яисә дәүләти яки муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең яки хезмәткәрләренең, оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең, вазифаи затларының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы)беләнкилешмәве нигезләнгәндәлилләре. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау өчен зур әһәмияткә ия булган документлар булмаганда яисә шикаятькә теркәлмәгән булса, карар шикаятьне раслаучы документлардан башка гына, дәлилләрне исәпкә алмыйча кабул ителә.

5.6. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең учредителенә, дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.1 өлештә каралган оешмаларга яисә югарыда торучы органга (булганда) килгән шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш,ә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.1 өлештә каралган документларын кабул итүдән баш тартканда яисә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү яисә билгеләнгән срокта мондый төзәтмәләргә карата шикаять биргән очракта аны теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять кабул ителгән карарны кире кагу, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү формасында, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе

субъектларының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаганакчаларны кире кайтару рәвешендә дә канәгатьләндерелә;

2)шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. 5.7 пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада җибәрелә.

5.8.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенү һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында ирешергә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яки 210-ФЗ Федераль законның 16 матдәсендәге 1.1 өлештә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.8.2. Шикаять канәгатьләнергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә бирелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре билгеләнгәндә, вазифаи зат, 210-ФЗ Федераль законның 11.2 матдәсендәге 1 өлеше нигезендә шикаятьне карау вәкаләтләре бирелгән хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары А. Н. Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**